Республики Татарстан
Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района

423643,РТ, Менделеевский
район, с.Камаево, ул. Дифгата Сирая
д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

От 2021 елның 1 нче апрелендә № 5

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл
җирлеге территориясен санитар-экологик
чистарту турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территорияләрен халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеге таләпләренә җавап бирә торган санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Камай авыл җирлеге территориясен чистарту буенча 2021 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр санитар-экологик икеайлык игълан итәргә.

2. Экологик икеайлык оештыру һәм үткәрү буенча оператив штаб составын расларга :

Штаб җитәкчесе:

Аглиева И. И. - Камай авыл җирлеге башлыгы.

Әгъза:

1. Иванова А. Ш. - Камай төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры»
2. Хайриев И. Р – - КФХ башлыгы Хайриев И. Р.
3. Әһлиев Д. Р. - КФХ башлыгы Әһлиев Д. Р.
4. Рәхимова Л. Н – - Камай авылы мәдәният йорты директоры
5. Галимуллина Г. М. – китапханәче

3. Камай авыл җирлеге территориясен санитар чистарту планын расларга. (1 нче кушымта).

4. Предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә 01.04.2021 елдан 30.09.2021 елга кадәр әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә , атналык «санитар чәршәмбе һәм өмәләр»не дә кертеп, беркетелгән территорияләрне җыештыру эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга  һәм /mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы И. И. Әһлиева

Камай авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 1
апрелендәге карарына
1 НЧЕ КУШЫМТА

Камай авыл җирлеге территориясен санитар чистарту ПЛАНЫ

| № п/п | Чара | үткәрү датасы | башкаручылар | җаваплы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак сектор һәм учреждениеләр территорияләрен чистарту | икеайлык дәвамында һәр атнаның чәршәмбесе һәм шимбәсе | Камай авылында яшәүчеләр һәм учреждениеләр, КФХ хезмәткәрләре | Учреждениеләр җитәкчеләре, КФХ башлыклары, торак йортларның милекчеләре |
| 2 | Юл буйларын чистарту | икеайлык дәвамында һәр атнаның чәршәмбесе һәм шимбәсе | учреждениеләр, КФХ хезмәткәрләре | Камай авыл җирлеге башкарма комитеты, учреждениеләр җитәкчеләре, КФХ башлыклары |
| 3 | Зиратны төзекләндерү | икеайлык дәвамында һәр атнаның чәршәмбесе һәм шимбәсе | Камай авылында яшәүчеләр һәм учреждениеләр, КФХ хезмәткәрләре | Камай авыл җирлеге башкарма комитеты, учреждениеләр җитәкчеләре, КФХ башлыклары |

Камай авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 1
апрелендәге карарына
2 НЧЕ КУШЫМТА

01.04.20021 елдан 30.09.20021 елга кадәрге чорда
бюджет учреждениеләренә беркетелгән территорияләр исемлеге

| № п/п | Учреждение исеме | Участок исеме | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | Камай төп гомуми белем бирү мәктәбе | 1. 1 Камай борылышыннан алып авылның беренче торак йортларына кадәр ( юл буенда утыртылган агачлар һәм зират буенда) юл буе полосасы<br>2. 2 Дифгать Сирая урамы буенча ташландык территорияләр (тулысынча)<br>3. Дифгать Сирай 1 нче йорттан М7 трассасына кадәр юл буе полосасы | Иванова А. Ш.<br>Аннамурадова Р. Б. |
| 2 | Мәдәният йорты, китапханә Камай авыл җирлеге башкарма комитеты | 1. Тынычлык урамы буенча ташландык территорияләр | Рахимова Л.Н.<br>Галимуллина Г. М.<br>Аглиева И. И. |